
- ачык урында яки аланда калсагыз, җиргә иелеп сулагыз - анда һава чистарак;



- авыз һәм борынны мамык-марля бәйләвече яки тукыма белән каплагыз;



- янгын зонасыннан чыкканнан соң янгынга каршы хезмәткә, торак пункт администрациясенә, урманчылыкка янгынның урыны, күләме һәм характеры турында хәбәр итегез.




**ЭКСТРЕМАЛЬ ХӘЛЛӘРДӘ ЯРДӘМ СОРАП КАЯ МӨРӘҖӘГАТЬ ИТӘРГӘ БУЛА**

Казан шәһәре буенча коткару хезмәте бердәм телефоны (кәрәзле телефоннан) **- 112**

ГТХМ һәм янгын хезмәте **- 101**

**Татарстан Республикасы ГО һәм ГТХ буенча укыту-методик үзәгенең ГО һәм ГТХ белгечләре һәм вазыйфаи затларны әзерләү бүлеге**



# УРМАН ЯНГЫНЫ КИЛЕП ЧЫККАНДА ГАМӘЛЛӘР ТӘРТИБЕ

**БЕЛЕШМӘЛЕК**

Казан ш.

Урманда янгын чыкмасын өчен, алдагы кагыйдәләрне үтәргә кирәк:

*кырларда һәм аланнарда коры үлән яндырмагыз;*

*коры урманда һәм торфлыкта учак кабызмагыз;*

*учак кабызганчы, җирне коры үләннән чистартыгыз;*

*китәр алдыннан учакка яхшылап су сибегез;*

*беркайчан да сүндерелмәгән шырпы яки тәмәке ташламагыз, урманда пиротехник эшләнмәләрен кабызмагыз;*

*урманга автомобиль, бигрәк тә мотоцикл белән кермәгез.*

Кагыйдә буларак, башта түбән янгын чыга, ул билгеле бер шартларда өске яки җир асты (торф) янгынына күчәргә мөмкин.

Әгәр янгын түбән яки локаль булса, аны мөстәкыйль рәвештә сүндерергә тырышырга була - яфраклы ботаклар ташлап, су агызып, грунт белән сибеп, аяклар белән таптап.



Янгын сүндергәндә уяу булыгыз, юллардан ерак китмәгез, башкаларны күз алдында тотыгыз, алар белән элемтәдә булыгыз.

Әгәр сезнең үз көчегез белән янгынны локальләштерү һәм сүндерү мөмкин булмаса, бигрәк тә өске яки җир асты янгыны булганда:

- барлык якын-тирәдәгеләрне куркыныч зонадан чыгу кирәклеге турында кисәтегез;



- кешеләрне юлга яки ерымга, киң аланга, елга яки сулык ярына, кырга чыгарыгыз;
- янган торфяниклар зонасыннан чыкканда, колга белән алдыгыздагы туфракны капшап барыгыз;



- куркыныч зонадан тиз, янгын юнәлеше сызыгына перпендикуляр чыгыгыз;



- аң һәм көчегезне югалтмас өчен, җиргә иелеп хәрәкәт итегез, түбәндә кислород күбрәк;



- әгәр янгыннан чыгу мөмкин булмаса, сулыкка керегез яки юеш кием белән капланыгыз;

